СОВЕТ САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

14.05.2020 с. Сарманово № 235

Советның 2012 елның 17 декабрендәге 99 номерлы карары белән расланган «Челтәр компаниясе» ААЖ энергетика объектларын чагылдыру өлешендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, Сарман муниципаль районы Уставы нигезендә Сарман муниципаль районы Советы карар чыгарды:

1. Муниципаль районны электр белән тәэмин итү схемасын эшләү юлы белән 2012 елның 17 декабрендәге 99 номерлы Совет карары белән расланган «Челтәр компаниясе» ААЖ энергетика объектларын чагылдыру өлешендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертергә.
2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Челтәр компаниясе» ААЖ энергетика объектларын чагылдыру өлешендә, муниципаль районны электр белән тәэмин итү схемасын эшләү юлы белән үзгәрешләр кертү буенча чаралар планын, чараларны үтәү срокларын расларга (1 нче кушымта).
3. Муниципаль районның электр белән тәэмин итү схемасын эшләү өлешендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү буенча эшләрне финанслау «Челтәр компаниясе» ААЖ акчасына башкарыла.
4. Советның 2012 елның 17 декабрендәге 99 номерлы карары белән расланган «Челтәр компаниясе» ААЖ энергетика объектларын чагылдыру өлешендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советының 2019 елның 29 апрелендәге 169 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Сарман муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль район Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Сарман муниципаль районы
Советы Рәисе Ф.М.Хөснуллин

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советының 14.05.2020 елның 235 номерлы карарына 1 нче кушымта

Чаралар планы

| № п/п | Чараның исеме | Үтәү вакыты | Җаваплы зат |
|---|---|---|---|
| 1 | Җирле үзидарәнең вәкаләтле органы тарафыннан техник заданиене раслау.<br>Муниципаль районның электр белән тәэмин итү картасының территориаль планлаштыру схемасын нигезләү буенча материалларны эшләү һәм өстәү өлешендә үзгәрешләр кертү проектын эшләүгә 3 яклы контракт төзү. | 2020 елның апрель аеннан май аена кадәр | Сарман муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече Гәрәев Рөстәм Рафаил улы |
| 2 | ТП ФГИСта муниципаль районны электр белән тәэмин итү схемасын эшләү юлы белән Сарман муниципаль районы картасын территориаль планлаштыру схемасын нигезләү буенча материаллар эшләү һәм тулыландыру өлешендә СТПга үзгәрешләр кертү проектын урнаштыру. | Проектны эшләүче тарафыннан җибәргәннән соң 5 эш көне эчендә | Сарман муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече Гәрәев Рөстәм Рафаил улы |
| 3 | СТПга үзгәрешләр кертү проектын раслау | СТПга үзгәрешләр кертү проектына Татарстан Республикасы Министрлар кабинетыннан уңай бәяләмә кабул ителгәннән соң бер ай эчендә | Сарман муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече Гәрәев Рөстәм Рафаил улы |